## УТЫР ӘЛЕ ЯННАРЫМА

*ИФРАТ ХИСАМОВ музыкасы*
*ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ сүзләре*

Оныт мәшәкатьләреңне.
Оныт инде беразга.
Сыйпап — сыйпап чәчләремне,
Бер иркәлә, бер назла.

*Кушымта*
Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.

Йөзләреңә төбәп карап,
Килә бер сөенәсем,
Килә бер иркәләнәсем,
Килә бер сөеләсем.

*Кушымта.*

Күзләремә ашыгып кына
Салкын карап үтмә син;
Өстәп тор сөю ялкынын,
Гел өсти тор, бетмәсен.

*Кушымта.*